| | |
|---|---|
| ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН», МЭР ГОРОДА ЛЕНИНОГОРСКА | «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МЭРЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

08.11.2024 г.Лениногорск № 93

2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына Лениногорск муниципаль районы бюджеты проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 17 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы халкының Лениногорск муниципаль районы бюджеты проектын тикшерүдә катнашу хокукларын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советының 2017 елның 30 маендагы 35 номерлы карары белән (15.12.2022 №70 үзгәрешләр белән) расланган Лениногорск муниципаль районында гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы яңа редакциядәге нигезләмәгә ярашлы рәвештә КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына Лениногорск муниципаль районы бюджеты проекты (алга таба – бюджет проекты) буенча ачык тыңлаулар үткәрергә.

2.Бюджет проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү инициаторы - Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты.

3. Билгеләргә:

гавами тыңлауларны үткәрү датасы һәм вакыты - 2024 елның 9 декабре 15.00 сәгатьтә;

гавами тыңлаулар уздыру урыны – Лениногорск шәһәре, Кутузов ур., 1 йорт, Лениногорск шәһәре мэриясенең утырышлар залы;

бюджет проекты буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, авторның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, яшәү урыны адресы күрсәтелгән адрес - Лениногорск шәһәре, Кутузов урамы, 1нче йорт, 4нче кабинет эш көннәрендә 8-00 сәгатьтән 16-00 сәгатькә кадәр тәкъдим ителә ала;

бюджет проекты буенча гаризалар кабул итү сроклары - 2024 елның 7 декабренә кадәр;

бюджет проектын халыкны таныштыру өчен Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru/) һәм Лениногорск шәһәре, Кутузов ур., 1нче йорт адресы буенча мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4. Лениногорск муниципаль районы Башкарма комитетына:

бюджет проекты буенча билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда гавами тыңлаулар оештырырга һәм уздырырга;

гавами тыңлаулар үткәрү йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советына гавами тыңлаулар беркетмәсен, гавами тыңлаулар тәкъдимнәрен, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә, шулай ук эшләп бетерелгән (үзгәрешләр кертелгән очракта) бюджет проектын тапшырырга;

2024 елның 13 декабренә кадәр бюджет проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтына (https://leninogorsk.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

5. Бюджет проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында хәбәрне 2024 елның 29 ноябреннән дә соңга калмыйча «Лениногорские вести» газетасында урнаштырырга.

6. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль
районы башлыгы урынбасары С.В.Тимаков

Сытдикова Д.Р.
5-04-00